СОВЕТ
СТАРОЧУКАЛИНСКОГО СЕЛЬСКОГО
ПОСЕЛЕНИЯ ДРОЖЖАНОВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЧҮПРӘЛЕ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ИСКЕ ЧОКАЛЫ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
СОВЕТЫ

---

Иске Чокалы

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

18 сентябрь 2017 ел № 21/2

Җир салымы турында

Россия Федерациясе Салым кодексы, Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Иске Чокалы авыл җирлеге Уставы нигезендә Чүпрәле муниципаль районы Иске Чокалы авыл җирлеге Советы карар кылды:

1.Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Иске Чокалы авыл җирлеге Советының «Җир салымы турында» гы карарын кушымта нигезендә яңа редакциядә расларга.

2.Әлеге карар 2018 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә, әмма рәсми рәвештә игълан ителгән көннән бер айдан да иртәрәк түгел.

3.Әлеге карар үз көченә кергәннән соң Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Иске Чокалы авыл җирлеге Советының түбәндәге карары үз көчен югалткан дип танырга:

1) 2016 елның 24 августыннан № 10/2 " Җир салымы турында».

Иске Чокалы авыл җирлеге
Башлыгы: Р.Р.Низамутдинов

Кушымта
Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Иске Чокалы авыл җирлеге Советының 18.09.2017 № 21/2 карары белән расланган

Җир салымы турында

Россия Федерациясе Салым кодексы һәм Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы авыл җирлеге Уставы нигезендә Чүпрәле муниципаль районы Иске Чокалы авыл җирлеге Советы КАРАР КЫЛДЫ:

1 Статья 1. Гомуми нигезләмәләр

Россия Федерациясе Салым кодексының 31 бүлеге нормалары нигезендә әлеге карар белән Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Иске Чокалы авыл җирлеге территориясендә мәҗбүри түләнергә тиешле җир салымы (алга таба - салым) билгеләнә һәм гамәлгә кертелә.

Статья 2. Салым ставкалары

Салым ставкалары түбәндәге күләмнәрдә билгеләнә:

1) торак фонды һәм торак-коммуналь комплексының инженерлык инфраструктурасы объектлары биләгән җир кишәрлекләренә карата кадастр бәясенең 0,1% ы (торак фондына һәм торак-коммуналь комплексның инженерлык инфраструктурасы объектларына керми торган объектка һәм торак төзелеше өчен сатып алынган (бирелгән) җир кишәрлегенә хокукындагы өлештән тыш);

2) шәхси ярдәмче хуҗалык, бакчачылык, яшелчәчелек яки терлекчелек, шулай ук дача хуҗалыгы өчен сатып алынган (бирелгән) җир кишәрлекләренә карата кадастр бәясенең 0,1% ы;;

3) торак пунктлардан читтә урнашкан җир кишәрлекләренең кадастр бәясенең 1,5% ы: сәнәгать, энергетика, транспорт, элемтә, радио, телевидение, информатика җирләре, космик эшчәнлекне тәэмин итү өчен җирләр, оборона, куркынычсызлык һәм башка махсус билгеләнештәге җирләр, оешмалар һәм учреждениеләр карамагындагы җирләр.;

4) башка җир кишәрлекләренә карата кадастр бәясенең 1% ы.

5) авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җирләргә яисә торак пунктларда авыл хуҗалыгы кулланылышы зоналары составына кертелгән һәм авыл хуҗалыгы җитештерүе өчен файдаланыла торган җир кишәрлекләренә карата кадастр бәясенең 0,3% ы;

6) 1-3 категорияле гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын төзү һәм эксплуатацияләү өчен җир кишәрлекләренә карата кадастр бәясенең 0,05% ы;;

Статья 3. Хисап чоры

Салым түләүче оешмалар өчен хисап чоры дип календарь елның беренче кварталы, икенче кварталы һәм өченче кварталы таныла.

Статья 4. Салым ташламалары

1. Авыл җирлеге территориясендә урнашкан, гражданнар күмелгән җир кишәрлекләренә карата оешмаларны, учреждениеләрне, Россия Федерациясе Салым кодексының 389 статьясында каралган очраклардан тыш, җир салымын түләүдән азат итү.

5 Статья. Салым һәм аванс түләүләрен түләү тәртибе һәм сроклары

1. Салым түләүче оешмалар өчен салым түләү беренче, икенче һәм өченче кварталлар беткәннән соң, 5 май, 5 август, 5 ноябрь, салым чоры булып торучы елның 1 гыйнварына җир кишәрлегенең кадастр бәясенең 1/4 процент өлешенең тиешле салым ставкасы күләмендә аванс түләүләре белән башкарыла.

Салым чоры йомгаклары буенча түләнергә тиешле салым суммасы узган салым чорыннан соң килүче елның 15 февраленнән дә соңга калмыйча түләнә.

Статья 6. Салым түләүчеләр тарафыннан салым салу базасын киметү хокукын раслый торган документларны тапшыру тәртибе һәм сроклары

Россия Федерациясе Салым кодексының 31 бүлеге нигезендә салым базасын киметү хокукын раслаучы документлар салым салу объекты дип таныла торган җир участогының урнашу урыны буенча салым органына узган салым чорыннан соң килүче елның 1 февраленә кадәр тапшырыла.

7 Статья. Җир кишәрлекләренең кадастр бәясен салым түләүчеләргә җиткерү тәртибе

Җир кишәрлекләренең дәүләт кадастр бәясен үткәрү нәтиҗәләре буенча, җир кишәрлекләренең кадастр бәясе календарь елның 1 гыйнварына Россия Федерациясе Хөкүмәте вәкаләт биргән федераль башкарма хакимият органы тарафыннан билгеләнә торган тәртиптә агымдагы елның 1 мартыннан да соңга калмыйча салым түләүчеләр игътибарына җиткерелергә тиеш.